СОВЕТ ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422150

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№ 2-19

Решение
«11» ноябрь 2022 ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» 14.10.2019 №3-47 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мамадыш районы прокуратурасы тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турындагы 14.10.2019 №3-47 карарына үзгәрешләр кертү турында» гы Советның модель акт проектын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ, 14.07.2022 ел, № 339-ФЗ 06.10.2003 «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль Законнарга таянып, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылуда катнашу турында»14.10.2019 №3-47 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 3 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырыга:
«13) нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү».
2. Әлеге карар 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Мамадыш муниципаль районының http:// mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Усманов Ф.М. ка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе вазыйфасын башкаручы: /Ф.М.Усманов/